КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 апрель г.Казань № 309

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшче яшьләр иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшче яшьләр иҗатының ел саен үткәрелә торган ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшче яшьләр иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче, 2018 ел, 24 август, 697 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшче яшьләр иҗатының ел саен үткәрелә торган ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 9 июнь, 386 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 19 апрель, 309 нчы
карары редакциясендә)

«Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасы эшче яшьләр иҗатының ел саен үткәрелә торган ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Наше время – Безнең заман» ел саен үткәрелә торган Татарстан Республикасы эшче яшьләр иҗаты ачык республика телевизион фестивалендә (алга таба – фестиваль) катнашучыларга куелган максат һәм бурычларны, үткәрү тәртибен, эчтәлекне, таләпләрне билгели.

1.2. Фестиваль ел саен җитештерү өлкәсе оешмаларының, сервис һәм хезмәт күрсәтү өлкәсенең төп эш урыны буенча кимендә 6 ай хезмәт стажы булган, алар тулы окладта булган эшләүче яшьләре арасында үткәрелә, алар өчен фестивальдә номинацияләр буенча катнашу һөнәри эшчәнлек төре булып тормый.

1.3. Фестивальдә катнашу өчен номинацияләр буенча һөнәри эшчәнлек төре булмаган мәдәният тармагы хезмәткәрләре фестивальдә катнашуга кертелмиләр.

1.4. Фестивальдә индивидуаль башкаручылар, иҗат коллективлары һәм оешмалар командалары катнаша ала. Фестивальдә команда катнашуы фестивальнең барлык номинацияләрендә мәҗбүри чыгыш ясауны күздә тота.

1.5. Бер оешма фестивальдә катнашу өчен бер генә команд бирә ала. Шәһәр, район, төрле оешмаларның җыелма командалары конкурста катнашуга кертелми.

2. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Фестивальне уздыруның максатлары булып түбәндәгеләр торалар:

эшче яшьләрнең рухи һәм интеллектуаль потенциалын, сәхнә талантларын һәм иҗади сәләтләрен ачу;

дәүләтнең милли байлыгы нигезен тәшкил итүче матди кыйммәтләр җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче яшьләрнең глобаль социаль инициативаларына ярдәм күрсәтү;

җитештерелгән продукция, хезмәт коллективы, хезмәт шартлары, матди кызыксындыру һәм социаль тәэминат белән һөнәри горурлык формалаштыру;

яшь хезмәткәрләрнең социаль адаптация дәрәҗәсен күтәрү, белем һәм гамәли күнекмәләрен камилләштерү өчен мөмкинлекләр спектрын киңәйтү.

2.2. Фестивальнең бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

эшләүче яшьләрнең сәләтләрен һәм булдыклылыгын уртак иҗади кызыксынулары мәйданчыгын формалаштыру;

эшче яшьләрнең мәдәни потенциалын популярлаштыру;

яшьләр даирәсендә куркыныч мавыгулар һәм социаль апатияне файдалы коллектив иҗаты, шәхси рухи һәм физик үсеш мөмкинлеге белән адекват алмаштыру;

республика оешмалары арасында иҗади элемтәләрне ныгыту, эшче яшьләрне профессиональ берләштерү процессына ярдәм итү;

традицион эшче һәм инженер белгечлекләренең интеллектуаль дәрәҗәсен күтәрү һәм җәлеп итүчәнлеген арттыру буенча һөнәри эшчәнлек тәҗрибәсен алмашу һәм яңаларын булдыру.

## 3. Фестивальне оештыру

3.1. Фестивальне әзерләү һәм үткәрү өчен оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3.2. Оештыру комитеты:

фестивальне әзерләү һәм үткәрү эшләрен координацияләүне гамәлгә ашыра;

фестиваль регламентын раслый;

зона турларын, зона турлары концертларын, фестивальнең финалын һәм гала-концертын үткәрү вакытын һәм урынын тәкъдим итә;

фестивальне оештыру һәм үткәрүдә финанс һәм мәгълүмати иганәчеләр катнашуның гомуми кагыйдәләрен һәм махсус шартларын раслый;

фестивальне финанс белән тәэмин итү мәсьәләләрен һәм оештыру мәсьәләләрен хәл итә;

бүләк фондының күләмен билгели;

жюри составын раслый;

әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Оештыру комитеты оператив мәсьәләләрне хәл итү өчен эшче төркемнәр булдырырга хокуклы.

3.3. «Созвездие – Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) (алга таба – Башкарма дирекция) законнарда билгеләнгән тәртиптә фестивальне үткәрүгә авторлык хокукына ия, ә аның җитәкчесе Башкарма дирекция боерыгы нигезендә фестивальнең генераль продюсеры булып тора.

3.4. Башкарма дирекция

фестивальне оештыру һәм үткәрү буенча оператив эш алып бара;

фестиваль программасын һәм символикасын раслый;

фестивальнең матбугат хезмәте массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрчеләрен һәм журналистларын аккредитацияләүне һәм озата баруны тәэмин итә, публикацияләрне җыю һәм анализлау эшен оештыра;

фестивальне әзерләү һәм уздыру чорында аның реклама кампаниясен үткәрә;

фестиваль чараларын һәм фестивальдә катнашучыларның иминлеген тәэмин итә;

фестивальне әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

фестивальнең зона турлары, финалы концертларының һәм гала-концерты сценариен һәм режиссурасын эшләү буенча иҗат төркеме составын раслый;

гаризалар кабул итүне һәм фестивальдә катнашучыларны сайлап алуны гамәлгә ашыра;

фестивальдә катнашу өчен тәкъдим ителгән документларның күчермәләренең чынлыгын тикшерү инициативасы хокукына ия;

фестивальдә катнашучыларның чыгышларын техник озата баруны тәэмин итә (профессиональ тавыш, яктылык җиһазлары);

фестивальнең зона турлары концертларының һәм гала-концерт репетицияләрен оештыра;

мәгълүмати тәэмин итү, өстәмә приз фонды булдыру, фестивальне оештыру һәм башка чыгымнар өчен түләү (акчалата яки башка формада) иганәчеләр җәлеп итәргә хокуклы.

3.5. Фестивальнең йомгаклау гала-концертын төшерү һәм трансляцияләү, зона концертларын трансляцияләү «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашырыла (килешү буенча), ул алга таба фестиваль идеяләрен һәм бурычларын популярлаштыру максатларында мәгълүмати продукция әзерләү өчен башкарма дирекциянең төшерелгән видеоматериалларының күчермәләрен тәкъдим итә.

## 4. Фестиваль турлары

4.1. Фестиваль зона турларыннан (концертлар белән ярымфиналлардан), финалдан һәм йомгаклау гала-концертыннан тора. Фестивальнең зона турларын үткәрү урыны һәм датасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән билгеләнә һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә фестивальнең рәсми сайтында www.bzzm.ru бастырыла.

4.2. Фестивальнең финалы Казан шәһәрендә үткәрелә. Фестиваль финалында фестивальнең зона турларында призлы урыннарга ия булган индивидуаль башкаручылар, иҗат коллективлары, шулай ук фестивальнең зона турының гомумкоманда зачетында призлы урын алган оешмалар командалары катнаша.

4.3. Фестивальнең генераль продюсеры жюри һәм Башкарма дирекция каравына финалга шәхси башкаручыны яки призлы урын алмаган иҗат коллективын чакыру турындагы тәкъдимен тәкъдим итәргә хокуклы.

## 5. Фестивальдә катнашу шартлары

5.1. Фестивальдә катнашу өчен катнашучыларга «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә фестивальнең рәсми сайтында www.bzzm.ru тәкъдим ителгән формалар буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гариза һәм ризалык тутырырга кирәк. Анкета-гариза җибәргән оешма җитәкчелеге исеменнән тутырыла. Оешма командасы яки иҗат коллективы анкета-гаризада катнашкан очракта, аның һәр әгъзасы күрсәтелә.

5.2. Фестивальне үткәрү һәм гаризалар кабул итү сроклары «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә фестивальнең рәсми сайтында www.bzzm.ru басылып чыга. Кабул итү срогы билгеләнгән соңрак килгән гаризалар карауга кабул ителми.

5.3. Фестивальдә җитештерү өлкәсе оешмаларының, сервис һәм хезмәт күрсәтү өлкәсенең төп эш урыны буенча кимендә 6 ай хезмәт стажы булган, тулы окладтагы 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге штат хезмәткәрләре генә катнаша ала, алар өчен фестивальдә катнашу номинация буенча һөнәри эшчәнлек төре булып тормый. Күрсәтелгән таләпкә туры килмәү ачыкланган очракта, катнашучы квалификациясеннән мәхрүм ителә.

5.4. Фестивальнең Башкарма дирекциясе бу фестивальдә катнашу катнашучы өчен һөнәри эшчәнлек төре булып тормау шартын тикшерү өчен катнашучылардан биләгән вазыйфасына туры килгән, оешма җитәкчесе яки оешманың кадрлар хезмәте җитәкчесе тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе (барлык битләр) күчермәсен һәм вазыйфаи инструкцияне соратып алырга хокуклы.

5.5. Җитештерү өлкәсе оешмаларының, сервис һәм хезмәт күрсәтү өлкәсенең төп эш урыны буенча кимендә 6 ай хезмәт стажы булган, тулы окладтагы 35 яшьтән 41 яшькә кадәрге штат хезмәткәрләре булган катнашучылар фестивальдә кимендә 4 кешедән торган иҗат коллективы составында катнаша ала. Әлеге яшь категориясендә катнашучылар саны иҗат коллективында катнашучыларның гомуми санының 25 процентыннан артмаска тиеш.

5.6. Фестивальнең зона турлары башланганчы фестивальдә катнашучыларның барысы да Башкарма дирекциягә оешма җитәкчесе яки кадрлар хезмәте җитәкчесе раслаган шәхесне таыклаучы документның, хезмәт кенәгәсенең, медицина иминияте полисының күчермәләрен, шулай ук фестивальдә катнашу өчен кирәкле фонограмма язмасын һәм реквизитларны тәкъдим итәләр.

5.7. Фестивальнең һәр катнашучысы фестивальнең барлык конкурс номинацияләрендә катнашырга хокуклы.

5.8. Фестиваль номинацияләре, номерларга һәм башкаручыларга төп таләпләр, шулай ук номинацияләр буенча бәяләү критерийлары фестивальнең оештыру комитеты раслаган һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә фестивальнең рәсми сайтында www.bzzm.ru бастырылган фестиваль регламенты белән билгеләнә.

5.9. Фестивальдә катнашучыларның чыгышлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә (10 балл – иң югары бәя, 3 балл – иң түбән бәя). Бәяләр куелганнан соң уртача балл чыгарыла.

Алынган уртача балл фестиваль регламенты нигезендә фестиваль номинацияләрендә җиңүчеләрне билгеләү буенча жюри тарафыннан фикер алышу һәм карар кабул итү өчен нигез булып тора.

5.10. Фестивальнең Гран-при финалның барлык номинацияләре нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган оешма командасына тапшырыла. Гомумкоманда нәтиҗәләрен исәпләп чыгарганда, фестивальнең һәр номинациясе буенча иң югары бәя бара (катнашучы командаларда баллар саны тигез булган очракта номинацияләр буенча бәяләр яңадан исәпләп чыгарыла). Казанышлар җыелмасы буенча җиңүчене билгеләү мөмкинлеге булмаган очракта, Гран-при жюри карары белән бирелә.

5.11. Алдагы сезон Гран-при иясе булган команда гомуми нигезләрдә фестивальдә катнаша ала. Әгәр мондый команда фестивальнең барлык номинацияләре буенча иң күп балл җыйган очракта, Гран-при иң күп балл җыйган киләсе командага тапшырыла.

## 6. Фестивальнең жюри

6.1. Фестивальнең жюри составы данлыклы һәм танылган артистлар, композиторлар, педагоглар, шагыйрьләр, продюсерлар, режиссерлар, журналистлар, иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, һөнәр берлекләре оешмалары вәкилләре, иҗади интеллигенция һәм эшмәкәрлек җәмәгатьчелеге, оешмалар вәкилләре, иганәчеләр һәм сәнгать меценатлары арасыннан Башкарма дирекция тәкъдиме буенча формалаштырыла.

6.2. Жюри регламентта билгеләнгән критерийлар нигезендә фестивальдә катнашучыларның чыгышларын карый, бәяли, шулай ук фестиваль номинацияләре буенча һәм Гран-при җиңүчеләрен билгели.

6.3. Фестиваль жюрие бер яки берничә номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны бирмәскә хокуклы.

6.4. Тавышлар тигез булган очракта жюри рәисе хәлиткеч тавышка ия. Жюри карары ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм жюри рәисе тарафыннан раслана.

6.5. Беркетмә белән рәсмиләштерелгән жюри карарлары ахыргы, яңадан карап тикшерелергә һәм шикаять бирелергә тиеш түгел.

## 7. Фестивальне үткәрү шартлары һәм катнашучыларның җаваплылыгы

7.1. Мәдәни һәм этика нормаларын үтәү максатыннан, фестиваль жюрие зона турларыннан, финалдан һәм фестивальнең гала-концертыннан эчтәлеге җәмгыятьтә кабул ителгән этик, мораль һәм социаль-мәдәни нормаларга туры килми торган номерларны төшерү хокукын калдыра.

7.2. Зона турларыннан, финалдан һәм фестивальнең гала-концертыннан номерлар алу турындагы карар ачык тавыш бирү юлы белән жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм жюри рәисе тарафыннан имзалана.

7.3. Фестивальдә катнашучы оешмаларга Башкарма дирекция хезмәткәрләре арасыннан кураторлар беркетелә. Кураторлар очрашулар, зона турларын үткәрү вакытлары һәм урыны турында мәгълүмат бирүне, фестиваль чараларына озата баруны оештыралар.

7.4. Фестивальне үткәрү буенча сораулар һәм тәкъдимнәр килеп туган очракта оешма җитәкчелеге вәкилләре оештыру комитеты яки Башкарма дирекция адресына язмача мөрәҗәгатьне электрон адреска: beznenzaman@mail.ru, Regina.Ahmetova@tatar.ru яки: 420111, Казан шәһәре, Карл Маркс урамы, 23/6 йорт адресына җибәрергә хокуклы.

7.5. Фестиваль вакытында барлыкка килә торган барлык бәхәсле һәм низаглы ситуацияләр тиешле оешма җитәкчелеге вәкилләре катнашында Башкарма дирекция тарафыннан хәл ителә.

7.6. Фестивальдә катнашучыларның фонограммалары фестиваль регламентында күрсәтелгән таләпләргә туры килергә һәм белешмәлекне теркәп, флеш-тупланмаларда Башкарма дирекциягә тәкъдим ителергә тиеш: фестивальдә катнашучы оешма исеме яки башкаручы исеме, номер исеме, трек номеры, хронометраж. Үзенчәлекле реквизит һәм музыкаль инструментлар, җиһазлар, коммутация (чыбык, кабельләр һ.б.) күрсәтелми.

7.7. Шәхси башкаручылар, иҗат коллективлары һәм оешмалар командалары әгъзалары фестиваль үткәрелә торган территориядә Башкарма дирекция һәм оешманың мөлкәтенә матди зыян китергән өчен шәхси җавап тота.

## 8. Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләү

8.1. Фестиваль җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы, фестивальнең Гран-при тапшыруны кертеп, фестивальнең йомгаклау гала-концертында башкарыла.

8.2. Фестивальнең зона турларының барлык җиңүчеләре дипломнар белән бүләкләнә.

Фестиваль финалында беренче, икенче һәм өченче урыннарны алган шәхси башкаручылар, иҗат коллективлары һәм командалар оештыру комитеты раслаган приз фонды акчалары хисабына акчалата премияләр ала. Беренче урыннарны алган иҗат коллективлары өстәмә рәвештә кубоклар ала.

8.3. Фестиваль Гран-при алган оешма командасына Татарстан Республикасы Президентының Күчмә кубогы һәм фестиваль җиңүчесе дипломы тапшырыла.

8.4. Фестиваль жюрие фестивальдә катнашучыларга оештыру комитеты раслаган приз фонды акчалары хисабына махсус бүләкләр бирергә хокуклы.

8.5. Фестиваль жюрие бер яки берничә номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны бирмәскә хокуклы.

8.6. Оештыру комитеты белән киештереп оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары махсус бүләкләр булдыру хокукына ия.